РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апреля 2024 ел г. Альметьевск № 1621

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген электрон формада торгларда милеккә, арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 743 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген электрон формада торгларда милеккә, арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 743 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 2 ноябрендәге 2543 номерлы, 2023 елның 4 августындагы 2692 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 2.8 бүлегенең 2.8.2.1 пунктындагы 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) җир кишәрлеге комплекслы үсеш турында шартнамә төзелгән яисә Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

заказ № 1-851